Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылы

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«23» ноябрь, 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Иске Дөреш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 (алты йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Боек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1). Зиратны төзекләндерү (материаллар сатып алу һәм урнаштыру)

2. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков